Казаклар Чаллысы авыл җирлеге башкарма комитеты
Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2016 елның 15 ноябре Казаклар Чаллысы ав. № 27

«2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» муниципаль программасын раслау турында

2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында», 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Казаклар Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. «2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең энергияне сак тоту һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген арттыру» муниципаль программасын (алга таба – Программа) расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге башкарма комитетын программаның заказчысы – координаторы итеп билгеләргә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең Казаклар Чаллысы авылы, Иванов урамы, 26 нчы йорт; Иванай авылы, Калинин урамы,18 йорт; Бирдебәк авылы, Мәктәп урамы, 5 йорт; Үри Чаллысы авылы, Гаврилов урамы, 24 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Башлыгы И.С.Ананьев

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 15 ноябрендә кабул ителгән 27 номерлы карары белән расланган.

**"2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру" муниципаль программасы**

**ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | "2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру" муниципаль программасы |
| Программаны эшләү өчен нигезләр | - «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»2009 елның 23 ноябрендәге 261 номерлы Федераль закон;<br>-Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә төбәк һәм муниципаль программаларга карата таләпләр турында»2009 елның 31 декабрендәге 1225 номерлы карары;<br>-Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру чаралары планын раслау турында»2009 елның 1 декабрендәге 1830-р номерлы күрсәтмәсе;;<br>- «Татарстан Республикасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру чаралары планын раслау турында»2010 елның 9 мартындагы 356-р номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе |
| Муниципаль заказчы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге башкарма комитеты |

| | |
|---|---|
| Эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Башкаручылар | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Программаның максаты-тормыш сыйфатын даими күтәргәндә һәм табигый ресурсларны саклаганда ягулык-энергетика ресурсларын нәтиҗәле куллануны тормышка ашыру |
| | Программаның бурычлары:<br>- энергияне сак тоту стратегиясен гамәлгә ашыру өчен оптималь норматив-хокукый, оештыру һәм икътисадый шартлар тудыру;<br>- энергияне саклау программаларын һәм проектларын финанслау һәм тормышка ашыру механизмнарын камилләштерү;<br>- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге икътисадын энергиядән нәтиҗәле файдалануны тәэмин итә торган прогрессив технологияләр, техника һәм материалларны булдыру һәм куллану; |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | Программа 2016-2020 еллар дәвамында тормышка ашырыла |
| Программа Чаралары Системасы | Төп программа чаралары:<br>- электр энергиясен тапшыру өчен файдаланыла торган хуҗасыз күчемсез милек объектларын ачыклау, мондый объектларны билгеләнгән тәртиптә хуҗасыз күчемсез милек объектлары буларак исәпкә куюны оештыру буенча чаралар;<br>- җиһазларны модернизацияләү буенча чаралар, шул исәптән инновацион карарлар һәм технологияләр кертү;<br>- электр энергиясе күләмен киметү буенча чаралар,<br>энергияне саклау технологияләрен гамәлгә кертү буенча чаралар;<br>- мотор ягулыгы сыйфатында транспорт чаралары кулланыла торган бензинны табигый газ белән алмаштыру чаралары, муниципаль берәмлек тарафыннан аларны ташу буенча хезмәтләр күрсәтүгә тарифларны җайга салу;<br>- бюджет учреждениеләре җитәкчеләренә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген |

| | |
|---|---|
| | арттыру буенча чаралар үткәрү кирәклеге турында хәбәр итү |
| Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы | Программаны тормышка ашыруны координацияләүне һәм тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге башкарма комитеты гамәлгә ашыра |
| Программаны финанслау чыганаклары | Гамәлдәге законнар белән тыелмаган Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары һәм башка чыганаклар |
| Планлаштырылган нәтиҗәләр | Программаны үтәү нәтиҗәсендә энергияне сак тоту буенча норматив-хокукый база булдырыла, энергияне сак тоту проектларын һәм программаларын тормышка ашыруның финанс-икътисади механизмнары эшли башлый. Энергияне сак тоту техникасын һәм технологияләрен гамәлгә кертү буенча проектлар гамәлгә ашырыла, икътисадның ресурслар нәтиҗәлелеге арта, зарарлы матдәләр чыгару кими, экологик хәл яхшыра |

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең ягулык-энергетика комплексы характеристикасы

1.1. Территориаль берәмлекне электр белән тәэмин итү
1.1.1. Энергияне сак тоту һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру программасын үтәү буенча планлаштырылган чаралар исемлеге
1.2. Территориаль берәмлекнең бюджет өлкәсен оештыру
1.2.1. Бюджет оешмаларының энергия куллануы кыскача характеристикасы
1.3. Территориаль берәмлекнең энергетика ресурсларын исәпкә алу һәм җайга салу приборлары
1.4. Территориаль берәмлекнең энергетика балансы һәм энергияне сак тоту потенциалы.

2. Программаның төп максатлары һәм бурычлары.

Әлеге программа Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең реаль секторында һәм бюджет өлкәсендә энергетик һәм башка матди ресурсларны куллануның нәтиҗәлелеген арттыру максатларына юнәлдерелгән.

2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру программасы энергия ресурсларын нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен билгели. Анда аларны үтәү сроклары, күләме һәм финанслау чыганаклары күрсәтелгән конкрет чаралар эшләнгән.

Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру программасын эшләү һәм тормышка ашыруның төп бурычлары булып тора:

Икътисад секторында энергия куллану нәтиҗәлелеген арттыруның тотрыклы процессын тәэмин итү,

Муниципаль берәмлек икътисады өлкәсендә энергияне сак тотуны стимуллаштыру һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру механизмнарын эшләтеп җибәрү,

Энергияне сак тоту потенциалын гамәлгә ашыруны тәэмин итүче энергоэффектив технологияләр, конструкцион һәм материаллар, энергия куллану белән идарә итү системаларын кертү;

Куллану процессында энергетика ресурсларын үлчәү һәм исәпкә алуның төгәллеген, дөреслеген һәм бердәмлеген тәэмин итү.

Программаның Бурычлары:

энергияне сак тоту стратегиясен гамәлгә ашыру өчен оптималь норматив-хокукый, оештыру һәм икътисадый шартлар тудыру;

энергияне сак тоту һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру программаларын һәм проектларын финанслау һәм гамәлгә ашыру механизмнарын камилләштерү;

авыл икътисадын энергия куллану нәтиҗәлелеген сыйфатлы яхшыртуны тәэмин итә торган прогрессив техника, технологияләр һәм материалларны булдыру һәм куллану.

## 3. ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУНЫҢ ОЕШТЫРУ-ИКЪТИСАДЫЙ МЕХАНИЗМНАРЫ

"Казаклар Чаллысы авыл җирлеге»муниципаль берәмлеген үстерү буенча производство программасы

Программа структурасы:

Кереш

II. Программаның максатлары

III. Программаның бурычлары

IV. Финанс белән тәэмин итү программасы

Кереш

«Казаклар Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең төп эшчәнлеге булып биналарның элементларына техник хезмәт күрсәтү, профилактика, кичектергесез ремонт ясау, биналарны инженерлык җиһазлары (җылыту, электр белән тәэмин итү, җайланмаларны да кертеп) системалары, шулай ук торак пунктның Тышкы төзекләндерү объектларын ремонтлау һәм карап тоту, җылылык белән тәэмин итү, электр белән тәэмин итү, электр белән тәэмин итү, инженерлык системаларын эксплуатацияләү тора.

"Казаклар Чаллысы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге
эшчәнлегенең төп күрсәткечләре

| | | |
|---|---|---|
| **Торак фонды** | Барлык мәйдан | 96,4 |
| | Йорт саны | 3 |
| **Юл-күпер хуҗалыгы** | Урамнарның, юлларның гомуми озынлыгы | 11,4 км |
| | Шул исәптән асфальтланган. | 1,1 км |
| **Электр белән тәэмин итү** | Җирлек территориясендә урнашкан нокталар саны | 63 шт. |
| **Газ белән тәэмин итү** | газ котеллары саны | - |
| | Газ казаннары саны | - |
| | Җылытыла торган биналарның саны | - |
| **Зиратлар** | саны | 2 |
| | Барлык мәйданы | 8 га |

1. Җылылык энергетикасы

Казаклар Чаллысы авыл җирлеге башкарма комитеты балансында котельныйлар юк.

II. Программаның максаты:

Җылылык энергетикасы

Җылылык бинасын реконструкцияләү, тузган агач тәрәзәләрне заманча пластик пыяла пакетка алыштыру күздә тотыла.

Әйләнә-тирә мохитнең пычрануы кимү, казаннарны тулысынча янып бетү буенча эшләрне башкарганнан соң була.

Электр энергетикасы

Балык Бистәсе муниципаль районының Казаклар Чаллысы авыл җирлеге территориясендә 63 урам яктырту ноктасы урнашкан. Чын нокталар электр лампалары белән тәэмин ителгән (ДРЛ), егәрлеге: 400 Вт буенча 4 лампа, 250 Вт буенча 27 лампа, 80 Вт лы 32 лампа. Программаны тормышка ашыру максатларында электр лампаларын энергия саклау ягыннан да, икътисади яктан да энергия саклый торган (60 Вт) га тулысынча алыштыру планлаштырыла.

## III. Программаның бурычлары

Җылыту бинасын реконструкцияләүне, аерым алганда: тузган агач тәрәзәләрне заманча пластик пыяла пакетка алыштыру күздә тотыла.

Электр лампаларын энергия куллану планында да, икътисади күзлектән дә энергия нәтиҗәлелеген арттырырга.

## IV. ДӘҮЛӘТ ИДАРӘСЕҺӘМ ПРОГРАММАНЫҢ ҮТӘЛЕШЕ БАРЫШЫН ТИКШЕРЕП ТОРУ

2016-2020 елларга энергияне сак тоту программасы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан эшләнгән, анда Энергия чыганакларына чыгымнарны экономияләү белән бәйле төп чаралар билгеләнгән.

Авылның бюджет учреждениеләре:

Авылда халыкка мәдәни хезмәт күрсәтүне Кече Әшнәк авыл клубы тәэмин итә, гомуми мәйданы 217 кв.м., 50 урын, хезмәткәрләр саны-1 кеше, гомуми фонды 100 мең данәдән артык булган 2 китапханә, 360 кв. м., 90 урынлы булган Казаклар Чаллысы авыл мәдәният йорты тәэмин итә. Казаклар Чаллысы мәдәният йорты хезмәткәрләре саны - 2 кеше.

Һәм 2016-2020 елларга билгеләнгән чаралар нигезендә гомуми чыгымнар 90000 мең сум тәшкил итәчәк, шул ук вакытта икътисади нәтиҗә 100 000 мең сум күләмендә алынырга тиеш.

## V. Төп программа чаралары
(ТКХ, бюджет оешмалары һәм сәнәгать предприятиеләрендә чаралар)

2016-2020 елларга мәдәният учреждениеләренең энергияне сак тоту һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру программасы белән Казаклар Чаллысы авыл мәдәният йорты бинасы каралган, иске агач тәрәзәләрне заманча пластик пыяла пакетка алыштыру күздә тотыла.

Чаралар буенча гомуми чыгымнар 150,0 мең сум тәшкил итәчәк.

Шулай ук электр энергиясен экономияле тоту Иске модификациядәге люминесцентлы лампаларны яңаларына алыштыру хисабына ирешелгән.

Мәдәни-мәгърифәти характердагы чаралар үткәрелә, учреждениеләрдә энергия ресурсларын рациональ һәм экономияле тоту буенча күрсәтмә әсбап әзерләү, ресурсларның экономияле тотылышын пропагандалау планлаштырыла.

## НӘТИҖӘ

Программа 2016-2020 елларда этаплап башкарылачак.

Беренче этапта уңай нәтиҗәне кичекмәстән алуга исәпләнгән беренче чираттагы чаралар гамәлгә ашырылачак.

Бюджет өлкәсендә энергия саклау һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру буенча соңгы нәтиҗә булып энергетика һәм матди ресурслардан

чагыштырмача файдалануны киметү, контингент һәм учреждение хезмәткәрләренә хезмәт күрсәтү өчен санитар-гигиена таләпләрен тәэмин итү тора.

Шулай итеп, программаны тормышка ашыру матди ресурсларны шактый экономияләргә тиеш.